ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз тугызынчы утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. «Татарстан Республикасы аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 367-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
2. «Татарстан Республикасында архив эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 360-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
3. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында» 366-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 359-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 71 статьясына үзгәреш кертү хакында» 200890-8 номерлы федераль закон проекты турында (бакалавриат һәм специалитет программалары буенча укырга кабул иткәндә, рәсми спорт ярышлары җиңүчеләренә аерым хокуклар бирү өлешендә).
6. «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законга үзгәреш кертү хакында» 232776-8 номерлы федераль закон проекты турында (тимер юлларда урнашкан күперләрне һәм тоннельләрне эксплуатацияләү хакында).
7. «Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{5}$ һәм $39^{10}$ статьяларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе

Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

8. 2022 елда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эше турында мәгълүмат.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2022 елның 16 декабре
№ 1747-VI ДС